КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 12 сентябрь г.Казань № 818

Казан шәһәренең урман-парк яшел поясын булдыру буенча ведомствоара эшче төркем турында

Казан шәһәренең урман-парк яшел поясын булдыру буенча килешенгән карар кабул итү һәм материаллар әзерләүне тизләтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәренең урман-парк яшел поясын булдыру буенча ведомствоара эшче төркем оештырырга.
2. Бу карарга теркәлгән Казан шәһәренең урман-парк яшел поясын булдыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне һәм аның составын расларга.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 12 сентябрь, 818 нче
карары белән расланды

Казан шәһәренең урман-парк яшел поясын булдыру буенча
ведомствоара эшче төркем турында
нигезләмә

1. Казан шәһәренең урман-парк яшел поясын булдыру буенча ведомствоара эшче төркем (алга таба – эшче төркем) Казан шәһәренең урман-парк поясын булдыру буенча килештерелгән карар кабул итү һәм материаллар әзерләүне тизләтү өчен оештырыла.

2. Эшче төркем Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән төзелә һәм бетерелә.

3. Эшче төркем үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

4. Эшче төркемнең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

Казан шәһәренең урман-парк яшел поясы чикләрен билгеләү, шулай ук урман-парк яшел поясына кертергә тәкъдим ителгән территорияләрнең «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры килү-килмәве мәсьәләләрен эшләү;

махсус саклана торган табигать территорияләрен һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне урман-парк яшел поясы чикләренә кертүнең максатка ярашлылыгы мәсьәләсен эшләү;

Казан шәһәренең урман-парк яшел поясын булдыру буенча материаллар әзерләү;

урман-парк яшел поясларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасының башкарма хакимият органын билгеләү буенча тәкъдимнәр кертү.

5. Эшче төркем үзенә йөкләнгән бурычларны башкару өчен федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан үз компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча материалларны һәм мәгълүматны законнар белән билгеләнгән тәртиптә соратып алырга хокуклы.

6. Эшче төркемгә йөкләнгән бурычларны башкаруны оештыру эшче төркемнең тигез хокукларга ия булган ике рәистәше тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7. Эшче төркем утырышлары кирәк булуга карап үткәрелә.

8. Эшче төркем карарлары эшче төркемнең утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә (тавышлар тигез булган очракта карарны эшче төркем рәистәше кабул итә) һәм утырышта катнашучы эшче төркем рәистәше тарафыннан утырыштан соң өч эш көне эчендә имзалана торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

9. Эшче төркем эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 12 сентябрь, 818 нче
карары белән расланды

Казан шәһәренең урман-парк яшел поясын булдыру буенча
ведомствоара эшче төркем
составы

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары – эшче төркем рәистәше |
| Гайзатуллин Ринат Рәүф улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе урынбасары – эшче төркем рәистәше (килешү буенча) |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Аллаһвердиев Руслан Бәһтияр улы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Үзәк территориаль идарәсе башлыгы урынбасары |
| Вафин Эдуард Марс улы | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты» муниципаль казна учреждениесе рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Зарипов Илгизәр Наил улы | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары |
| Козловская Татьяна Анатольевна | Казан шәһәре башкарма комитетының «Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитеты» Казан шәһәре муниципаль казна учреждениесе рәисенең беренче урынбасары (килешү буенча) |
| Костин Артем Петрович | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Кудряшев Владимир Николаевич | Татарстан Республикасының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Латыйпова Венера Зиннәт кызы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының Икътисадый үсеш, гражданнарның тормыш эшчәнлеге инфраструктурасы комиссия әгъзасы, югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Экология һәм табигатьтән файдалану институтына караган гамәли экология кафедрасы профессоры (килешү буенча) |
| Никитин Александр Владимирович | Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасы эксперты, югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Экология һәм табигатьтән файдалану институтына караган экологик проектлаштыру бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Романова Венера Габделбари кызы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә караган генераль план бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Садовникова Ольга Владимировна | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы |
| Фәсхетдинов Марат Гайсә улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының җир асты байлыкларыннан файдалану, табигать ресурслары һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы |
| Хәбибуллин Тимур Рифхәт улы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының кадастр мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы |
| Хәсбиев Раил Равил улы | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Хисаметдинов Рөстәм Рәшит улы | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Шакиров Фаяз Фәнил улы | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрының беренче урынбасары |
| Шәяхмәтов Илһам Данил улы | «РОССИЯ ӨЧЕН» ХАЛЫК ФРОНТЫ» бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан Республикасындагы төбәк башкарма комитеты эксперты (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Штейн Эдуард Андреевич | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының башкарма комитеты җитәкчесе беренче урынбасары (килешү буенча) |
| Ячанова Наталья Васильевна | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының баш агрономы (килешү буенча). |